ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» Татарстан Республикасы Законының 7 һәм 8 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 79-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары А.А. Чубаров һәм Э.С. Шәрәфиев тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» Татарстан Республикасы Законының 7 һәм 8 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 79-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2025 елның 11 июне
№ 314-VII ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
А.А. Чубаров, Э.С. Шәрәфиев
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» Татарстан Республикасы Законының 7 һәм 8 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» 2017 елның 27 апрелендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 33 (I өлеш); 2018, № 54 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 81 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 7 статьяның 4 өлешендә «бер ай эчендә» сүзләрен «30 көн эчендә» сүзләренә алмаштырырга;

2) 8 статьяда:

а) 1 өлештә «Дәүләт Советы» сүзләреннән соң «, әлеге статьяның $7^1$ өлешендә каралган очрактан тыш,» сүзләрен өстәргә, «бер ай эчендә» сүзләрен «30 көн эчендә» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле $7^1$ өлеш өстәргә:

«$7^1$. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган Иҗтимагый палата әгъзасы урынына Иҗтимагый палатаның яңа әгъзасын раслау турында карар кабул итү срогы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы сессияләре арасындагы чорда тәмамланса, Дәүләт Советы Иҗтимагый палатаның яңа әгъзасын раслау турындагы карарны әлеге срок тәмамланганнан соң якындагы утырышта кабул итәргә хокуклы.»;

в) 8 өлештә «бер ай эчендә» сүзләрен «30 көн эчендә» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» Татарстан Республикасы Законының 7 һәм 8 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

**АҢЛАТМА**

«Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» Татарстан Республикасы Законының 7 һәм 8 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты «Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» 2017 елның 27 апрелендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (алга таба – Татарстан Республикасы Законы) аерым нормаларын камилләштерүгә һәм төгәлләштерүгә юнәлдерелгән.

Татарстан Республикасы Законының «Иҗтимагый палата составын раслау» 8 статьясының 1 өлешендә Татарстан Республикасы Рәисе һәм Дәүләт Советы Иҗтимагый палата составына оешмалар вәкилләрен кертү турында гаризалар кабул итү туктатылган көннән алып бер ай эчендә Иҗтимагый палата әгъзаларын раслый дип билгеләнә.

Закон проекты белән 8 статьяга, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган Иҗтимагый палата әгъзасы урынына Иҗтимагый палатаның яңа әгъзасын раслау турында карар кабул итү срогы (Татарстан Республикасы Законының 8 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән) Татарстан Республикасы Дәүләт Советы сессияләре арасындагы чорда (парламент каникуллары чорында) тәмамланса, мондый раслау тәртибен күздә тотучы норма ($7^1$ өлеш) өстәү тәкъдим ителә. Закон проекты белән мондый очракта Дәүләт Советы Иҗтимагый палатаның яңа әгъзасын раслау турындагы карарны әлеге срок тәмамланганнан соң якындагы утырышта кабул итәргә хокуклы дип билгеләнә.

Моннан тыш, срокларны исәпләүдә төрле алымнарны бетерү максатларында «Иҗтимагый палата әгъзаларына кандидатлар күрсәтү тәртибе» 7 статьясында һәм 8 статьяда терминология төгәлләштерелә: «бер ай эчендә» кулланыла торган сүзтезмәне «30 көн эчендә» сүзләренә алмаштыру тәкъдим ителә.

**«Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» Татарстан Республикасы Законының 7 һәм 8 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» Татарстан Республикасы Законының 7 һәм 8 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарына үзгәрешләр кертүне, аларның үз көчләрен югалтуын тануны, аларны туктатып торуны, яисә башка Татарстан Республикасы законнарын кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» Татарстан Республикасы Законының 7 һәм 8 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

## ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ

«Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» Татарстан Республикасы Законының 7 һәм 8 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә акчалар бүлеп бирүне таләп итми.